ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Казан ш. № 514-206/кс-2020

«Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2021 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ) тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, иректә файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 №514-206/кс-2020
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2021 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Лениногорск муниципаль районы | | | | |
| | «Ленингорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ | | | | |
| 1 | Лениногорск шәһәре кулланучылары | | | | |
| 1.1. | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 31,62 | 32,02 | 2057,45 | 2092,40 |
| 1.2. | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 26,35 | 26,68 | 1714,54 | 1743,67 |
| 2 | Иске Иштирәк авыл җирлеге кулланучылары | | | | |
| 2.1. | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 20,36 | 20,36 | 2057,45 | 2092,40 |
| 2.2. | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 16,97 | 16,97 | 1714,54 | 1743,67 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге